ГЛАВА АКБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Гоголя, д.1, с.Акбаш, 423958

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ АКБАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Гоголь урамы, 1йорт, Акбаш авылы, 423958

Тел/факс: (85593) 4-14-34, e-mail: Akbash.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 1** **«11» ноября 2019 г.**

«Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең Акбаш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану соравы буенча халык җыенын билгеләү турында»

2003 елның 6 октябреннән «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» № 131 Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Уставының 14 статьясына ярашлы, Ютазы муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2019 елның 23 ноябренә 18.00 сәгатьтә Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең Акбаш торак пунктында Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Акбаш торак пункты, Мәктәп урамы, 17 адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында үзара салым кертү соравы буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

Сез 2020 елда Ютазы муниципаль районының Акбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешенең 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүенә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия сорауны хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

-Акбаш авылының Мәктәп урамы буенча юлны асфальтлауга

« ӘЙЕ» “ЮК".

2. Акбаш авыл җирлеге Башкарма Комитетына халык җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, һәм карар рәсми кабул ителгән көннән соң, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга, 5 көн эчендә Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга .

4. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Акбаш авыл җирлеге Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы: Сөнәгатуллина Л.Р.